КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 декабрь г.Казань № 1277

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Созвездие – Йолдызлык» еллык ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивален үткәрү турында» 2018 ел, 20 гыйнвар, 20 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Созвездие – Йолдызлык» еллык ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивален үткәрү турында» 2018 ел, 20 гыйнвар, 20 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 19 апрель, 263 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының» сүзләренә алыштырырга;

5 нче пунктта «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгына» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган «Созвездие – Йолдызлык» еллык ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивален үткәрү турындагы нигезләмәдә:

1 бүлектә:

беренче абзацта «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгы» сүзләренә алыштырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгы» сүзләренә алыштырырга;

4 бүлекнең 4.1 нче пунктындагы икенче абзацында «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгы» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган «Созвездие – Йолдызлык» еллык ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивален әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) составында:

оештыру комитеты составыннан В.А.Леоновны, Р.М.Гарифуллинны, А.Р.Зариповны, Э.Р.Камалованы, С.А.Осиповны чыгарырга;

оештыру комитеты составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы яшьләр эшләре буенча министры, оештыру комитеты рәисе урынбасары Дамир Илдус улы Фәттаховны;

Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары Альмир Рәшит улы Абашевны;

Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасары Юлия Илдар кызы Әдһәмованы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә караган физик культура һәм спортны үстерү мәсьәләләре бүлекчәсе мөдире Раушан Булат улы Зариповны;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәетгәрәй улы Сәлимгәрәевны;

Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрының беренче урынбасары Тимур Җәүдәт улы Сөләймановны.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин